**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 27 сентябрь № 686

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә, шул исәптән универсаль электрон карталардан файдаланып, күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 28 октябрь, 864 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 7 август, 674 нче; 2013 ел, 14 февраль, 103 нче; 2013 ел, 30 ноябрь, 936 нчы; 2014 ел, 9 июль, 479 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат үзәге турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3 нче пунктның «а» пунктчасында алтынчы абзацны төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмәне раслау хакында» 2016 ел, 9 июнь, 374 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре порталы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин